

Ләмберә районында республикада беренче тапкыр умартачылык очен кирәкле булган әйберләрне житештерv буенча (балавыздан нечкә бит- вощина) «Маргарита – 1» жайланмасы монтажланган.
Үзебезнен илдә житештерелгән жи-һазлар республика умартачылары кооперативы акчасына сатып алынган.

Республика умартачылары жәмгыяте рәисе, жибәрv-койләv эшләрен башкаручы тәжрибәле белгеч Сергей Васильевич Юматов жайланмалар эшләv принциплары турында сойләгән.
Беренчедән, vзебезнен илдә житеш-терелгән жиһазлар Энгельс шәһәрендә сатып алынган. Чит илнекеләр белән чагыштырганда, мәсәлән, кытайлылар, немец һәм чехлыларга караганда, безнен бәясе ягыннан отышлы булуы белән аерылып тора. Чит илдән кертелгән продукция дvрт тапкыр кыйммәтрәк. Остәвенә, шул огрегатта безнен хезмәткәрләрне ойрәтергә була һәм монын очен чит ил белгечләрен жәлеп итәргә кирәк тә тvгел- бу яктан да арзан.
Илебездә житештерелгән «Маргарита-1» елына 50 тонна продукция житештерә. Бу Мордовия умартачылары очен шактый озакка житә, ә алар - оч менгә якын. Вощина житештерv буенча жиһазларнын бәясе 1 миллион 300 мен сум. Мордовиядә ике умартачы- А.П.Папасов белән А.Н.Потапов умартачылык юнәлешендә КФХны vстерvгә 4әр миллион сум кvләмендә грантлар алдылар. Шулай итеп, аларнын һәркайсы алынган суммадан әйбер ясау буенча гына тvгел, балны зур булмаган порцияләргә тутыру буенча да жиһазлар сатып алуга шактый акча керткәннәр. Балны кечкенә савытларга тутыру машинасы 700 мен сум тора.
- Технологиябезнен ин моһим остенле-ге шунда, - дип анлата Сергей Васильевич,- һәр умартачынын vз балавызыннан куәтле әйбер алуы, бу сыйфатлы чимал алу очен бик тә унай. Шулай да балавызда барыбер гербицидлар, пестицидлар, антибиотиклар туплана. Нәтижәдә, бал кортлары vрчеми һәм vлә. Без парафин, церезин кебек ясалма препаратлар урынына балавызны эшкәрткәндә органик препаратлардан кулланабыз, бу безнен продуктнын сыйфатын шактый яхшырта, бал чыгу арта, умарта кортларынын баш саны саклана.
Шундый ук жиһазлар Германиядә, Чехиядә бар, әмма хәзер санкцияләргә бәйле рәвештә, безгә житми. Үзебезнеке бер-ничә тапкыр арзанрак, технологик параметрлар буенча охшаш. Импорт-ны алыштыру безнен умартачыларга файдага бара. Нигә дип

сорарсыз? Безнен продукция экологик яктан чиста, ә чит илдә ана ирешv бик авыр. Чонки андагы басуларга гербицидлар, пестицидлар, антибиотиклар бездәгегә караганда кvбрәк кvләмдә чыгарыла.
Илдә балавыздан вощина ясау бик авыр бара. Безнен схема буенча Ярославльдә генә, минемчә, аны житештерvне жайга салганнар. Менә без бу хәлне Мордовия очен генә булса да жайларга булдык. Кадошкино районынын бер фермеры вощина житештерv очен жиһазлар сатып алу нияте бар дип ишеттек, әмма ул шәхси максатларда гына житештерv технологиясен башлап жибәрергә планлаштыра. Безнен «Маргарита-1» жайланмасы республиканын барлык умартачылары ихтыяжларын тәэмин итvгә юнәлдерелгән.

**Н.ХӘЛИЛ**